**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4691**
**12.07.2021**

«85 нче психологик-медицина-социаль ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмә, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «85 нче психологик-медицина-социаль ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 12 июлендәге
4691 номерлы карарына
кушымта

«85 нче психологик-медицина-социаль ярдәм үзәге»
муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Контингент | Бәясе |
|---|---|---|---|---|
| | Белем бирү һәм үстерү хезмәтләре | | | |
| 1. | Шәхси үзенчәлекләрне, ресурсларны һәм куркынычларны тирәнтен диагностикалау – ата-аналарның һәм 15 яшьтән зуррак яшүсмерләрнең соравы буенча | 45 мин./кеше | балалар | 445,00 |
| 2. | Балалар белән гомуми психофизик, психоэмоциональ, танып-белү үсешенә һәм балаларны мәктәпкә әзерләүгә юнәлдерелгән индивидуаль гомумүстерү дәресләре | 30 мин/кеше | балалар | 350,00 |
| 3. | Балалар белән гомуми психофизик, психоэмоциональ, танып-белү үсешенә һәм балаларны мәктәпкә әзерләүгә юнәлдерелгән индивидуаль гомумүстерү дәресләре | 45 мин./кеше | балалар | 510,00 |
| 4. | Норматив йөкләмәләрдән тыш, укытучы-логопедлар, педагог-психологлар, укытучы-дефектологлар, социаль педагоглар, медицина хезмәткәрләре тарафыннан, шул исәптән белем бирү процессында катнашмаучы затлар өчен үткәрелә торган диагностика һәм консультацияләр | 60 мин./кеше | балалар | 435,00 |
| 5. | Профориентация диагностикасы һәм консультация бирү | 60 мин/төркем | балалар (8 кешегә кадәр төркем) | 800,00 |
| 6. | Белем бирү учреждениеләренең заявкалары буенча башлангыч сыйныф укучыларына психологик-педагогик скрининг үткәрү | 60 мин/төркем | балалар (15 кешегә кадәр төркем) | 1070,00 |
| 7. | Зурларга психологик консультация бирү | 60 мин./кеше | зурлар | 600,00 |
| 8. | Төркемле һәм индивидуаль гаилә психокоррекциясе; балалар һәм ата-аналар мөнәсәбәтләрен коррекцияләү | 60 мин./кеше | зурлар, балалар | 600,00 |
| 9. | Эксперт-диагностика эшчәнлеге, шул исәптән баланың яшәү урынын, бала белән аралашу тәртибен билгеләү турында, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, чикләү һәм аларны торгызу турында гаилә эшләрен карап тикшергәндә судьяларның запрослары буенча | 60 мин/кеше | зурлар, балалар | 600,00 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Башка хезмәтләр | | | | |
| 10. | Үзәк эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча педагоглар һәм психологлар өчен укыту семинарлары һәм стажировка | 60 мин./төркем | зурлар (10 кешегә кадәр төркем) | 700,00 |
| 11. | Коррекцион-үсеш белеме бирү, гамәли психология һәм балаларны социаль-педагогик тернәкләндерү өлкәсендә психологларның, социаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү курслары үткәрү | 45 мин./төркем | зурлар (10 кешегә кадәр төркем) | 600,00 |
| 12. | Зурлар белән төркемле тренинг дәресләре | 60 мин/төркем | балалар (10 кешегә кадәр төркем) | 540,00 |
| 13. | Йомгаклау аттестациясе һәм белем алу һәм (яки) квалификация турында документлар бирү каралмаган төрле лекцияләр, стажировкалар, семинарлар һәм укытуның башка төрләрен үткәрү | 45 мин./төркем | зурлар (15 кешегә кадәр төркем) | 605,00 |
| 14. | Шәхси үзенчәлекләрне, ресурсларны һәм куркынычларны тирәнтен диагностикалау; мөнәсәбәтләр системасы – зурлар өчен | 60 мин/төркем | зурлар | 600,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева